| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет<br>Нижнеуратьминского сельского поселения<br>Нижнекамского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Түбән Кама муниципаль районы<br>Түбән Уратмаавыл жирлеге<br>Советы |
| --- | --- |
| 423567, Нижнекамский район,<br>с. Нижняя Уратьма ул. Центральная, 1 | 423567, Түбән Кама районы,<br>Түбән Уратма авылы, Үзәк урамы, 1 |

тел./факс (8555) 33-17-25, электронный адрес: Nizhneuratminskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.nizhneuratminskoe-sp.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2020ел № 5

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге Советының 2012 елның13декабрендәге25номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге Уставының 62 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Түбән Кама муниципаль районы Советына тапшыру турында килешүләрне раслау хакында» 2018 елның 17 маендагы 37 номерлы карарына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы Советының 2012 елның 20 декабрендә кабул ителгән 68 номерлы « Түбән Кама муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренеңкоррупцион хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 21 февралендәге 18 номерлы карарын игътибарга алып, Түбән Уратма авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Түбән Уратма авыл җирлеге Советының 2012 елның 13 декабрендә кабул ителгән 25 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Түбән Уратма авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Р.Гарифуллин